КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 29 август г.Казань № 709

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеген индикатив бәяләү турында» 2023 ел, 29 декабрь, 1745 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеген индикатив бәяләү турында» 2023 ел, 29 декабрь, 1745 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 3 апрель, 225 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2024 елга һәм 2025 елның план чорына Татарстан Республикасының тулы вәкаләтле, даими, сәүдә-икътисад вәкиллекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларында:

«Татарстан Республикасының Төркмәнстандагы вәкаләтле вәкиллеге» бүлегенең «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» юлындагы бишенче графасында «ел саен» сүзләрен «квартал саен» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасының Әзербайҗандагы даими вәкиллеге» бүлегенең «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» юлындагы бишенче графасында «квартал саен» сүзләрен «ел саен» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасының Дубайдагы (Берләшкән Гарип Әмирлекләре) Тулы вәкаләтле вәкиллеге» бүлегенең «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» юлындагы бишенче графасында «ел саен» сүзләрен «квартал саен» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасының Лейпциг шәһәрендәге сәүдә-икътисад вәкиллеге» бүлегеннән соң түбәндәге эчтәлекле «Татарстан Республикасының Беларусь Республикасындагы сәүдә-икътисад вәкиллеге» бүлеген өстәргә:

«Татарстан Республикасының Беларусь Республикасындагы сәүдә-икътисад вәкиллеге

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (җыелма индикатор) | Вәкиллекнең мәҗбүри функцияләрен үтәү | - | 40 | квартал саен | үтәлде / үтәлмәде | үтәлде / үтәлмәде | үтәлде / үтәлмәде | үтәлде / үтәлмәде | үтәлде / үтәлмәде |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | Чит илләр предприятиеләре һәм Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында Татарстан Республикасы вәкиллеге ярдәмендә төзелгән һәм (яисә) гамәлгә ашырылган контрактлар саны буенча план үтәлеше, контрактлар саны | 7 | 10 | квартал саен | - | - | 2 | 5 | 10 |
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы продукциясен читтән кертү буенча эшлекле элемтәләр урнаштыру, элемтәләр саны | 2 | 10 | квартал саен | - | - | 1 | 1 | 4 |
| Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | Татарстан Республикасы вәкиллекләре ярдәмендә татар иҗтимагый оешмалары тарафыннан урыннарда үткәрергә планлаштырылган чаралар үтәлеше, чаралар саны | 3 | 10 | ел саен | - | - | - | 1. Татар иҗтимагый оешмаларына урыннарда «Сабантуй» халык бәйрәмен оештыруда һәм уздыруда ярдәм күрсәтү.<br>2. Татар иҗтимагый оешмаларына Беларусь Республикасында Татарстан Республикасы көненә багышланган чараларны оештыруда һәм уздыруда ярдәм күрсәтү.<br>3. «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасы нигезендә Беларусь һәм Россия халыкларын берләштерү көнен | 3 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | (2 апрель) үткәрүдә ярдәм күрсәтү | |
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | Медицина ярдәме күрсәтүгә юнәлдерелгән пациентлар саны, кеше саны | 100 | 10 | ел саен | - | - | 50 | 50 | 250 |
| Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты | Татарстан Республикасының туристлык потенциалы күрсәтелгән чаралар (күргәзмәләр, презентацияләр, форумнар, очрашулар һәм башкалар) саны, чаралар саны | 3 | 10 | ел саен | - | - | - | 1. Профильле чараларда катнашу, Татарстан Республикасының туристлык потенциалын презентацияләү һәм Татарстан Республикасының туристлык мөмкинлекләре турында мәгълүмат тарату.<br>2. Беркетелгән территориядә туроператорлар һәм журналистлар белән элемтәләрне җайга салуда ярдәм күрсәтү.<br>3. Ватандашларга Татарстан Республикасында үткәрелә торган күргәзмә-ярминкә, презентация, вакыйга һәм туризм өлкәсендәге башка чаралар турында мәгълүмат бирү | 3 |
| Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы | Татарстан Республикасының инвестицион потенциалы буенча презентацияләр үткәрү, презентацияләр саны | 3 | 10 | ел саен | - | - | - | 3 | 6»; |

әлеге карар белән расланган 2024 елга Татарстан Республикасының вәкаләтле, даими, сәүдә-икътисад вәкиллекләренең республика башкарма хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлеге күрсәткечләрендә «Татарстан Республикасының Лейпциг шәһәрендәге сәүдә-икътисад вәкиллеге» бүлегеннән соң түбәндәге эчтәлекле «Татарстан Республикасының Беларусь Республикасындагы сәүдә-икътисад вәкиллеге» бүлеген өстәргә:

| «Татарстан Республикасының Беларусь Республикасындагы сәүдә-икътисадый вәкиллеге» | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (җыелма индикатор) | 40 |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 10 |
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 10 |
| Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 10 |
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 10 |
| Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты | 10 |
| Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы | 10». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин